ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2023, № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), № 79 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьяның 14 пунктында «һәм юл буе полосаларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) $13^1$ статьяның $2^1$ өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«$2^1$. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән дәүләт учреждениеләрендә һәм муниципаль учреждениеләрдә инспектор вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләре хезмәт законнары таләпләре нигезендә билгеләнә.»;

3) 26 статьяда:
а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Юл буе полосалары, дүртенче һәм бишенче категория автомобиль юлларыннан һәм торак пунктлар чикләрендә урнашкан автомобиль юлларыннан тыш, автомобиль юллары өчен билгеләнә.»;

б) 7 өлештә «автомобиль юлы хуҗасының язма ризалыгы» сүзләрен «автомобиль юлы хуҗасы белән язма килештерү» сүзләренә алмаштырырга, «ризалыкта» сүзен «килештерүдә» сүзенә алмаштырырга;

в) $7^1$ өлештә «килешүсез» сүзен «килештерүсез» сүзенә алмаштырырга;

г) $7^2$ өлештә «ризалыкта» сүзен «килештерүдә» сүзенә алмаштырырга, «төзүгә, реконструкцияләүгә әлеге статьяның 7 өлеше нигезендә ризалык алу» сүзләрен «төзүне, реконструкцияләүне әлеге статьяның 7 өлеше нигезендә килештерү» сүзләренә алмаштырырга;

д) $7^3$ өлештә «төзүгә, реконструкцияләүгә ризалык бирү» сүзләрен «төзүне, реконструкцияләүне килештерү» сүзләренә алмаштырырга;

е) 8 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 01 март
№ 8-ТРЗ